Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Сухрау авыл җирлеге составына керүче Смыловка торак пунктында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2019 елның 23 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Сухрау авыл җирлегенең Смыловка торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Сухрау авыл җирлеге Смыловка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1нче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарны, көндезге уку формасы буенча белеем алучы студентлардан тыш, 200 сум күләмендә 2020 елда үзара салым кертергә, әлеге сумманын 50% күләмендә 2 нче төркем инвалидар һәм 80 яшьтән узганнар түли.
2. Алынган акчаларны Смыловка авылында пожар гидрантын урнаштыруга юнәлдерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Сухрау авыл җирлеге Р.Р.Галимов